| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 30.11.2015 г. Казань № 5-53/тэ

2016-2018нче елларга «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелгән җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016-2018нче елларга календарь чорларына бүлеп «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелгән җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифларны әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2016 елның 1 гыйнвареннан 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. 2016-2018 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулын кулланып тарифларны формалаштыру өчен, җайга салуның озак вакытка исәпләнгән чорына тәгаенләнеп, озак вакытка исәпләнгән җайга салу параметрларын әлеге карарның 2 кушымтасына нигезләнеп билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
30.11.2015 № 5-53/тэ
карарына 1 кушымта

# 2016-2018нче елларга календарь чорларына бүлеп, «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелгән җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, җайга салучы оешма исеме | Тариф төре | Ел | Җылылык йөртү төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | Пар |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифларга дифференциация ясалмаган очракта | | | |
| | | Бер ставкалы, сум./Гкал | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 558,77 | - |
| | | | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | 1228,41 | - |
| | | | 01.01.2017 алып 30.06.2017 кадәр | 909,19 | - |
| | | | 01.07.2017 алып 31.12.2017 кадәр | 938,69 | - |
| | | | 01.01.2018 алып 30.06.2018 кадәр | 938,69 | - |
| | | | 01.07.2018 алып 31.12.2018 кадәр | 976,28 | - |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
30.11.2015 № 5-53/тэ
карарына 2 кушымта

2016-2018 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулын кулланып
тарифларны формалаштыру өчен, җайга салуның озак вакытка исәпләнгән чорына тәгаенләнеп,
озак вакытка исәпләнгән җайга салу параметрлары

| № п/п | Муниципаль берәмлек, җайга салынучы оешма атамасы | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Табышларның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | ягулыкның чагыштырма чыгымы | җылылык челтәрен матди харак-теристикалауга карата югалтулар зурлыгы | технологик югалтулар |
| | | | мең сум | % | % | кг ш.я./Гкал | Гкал/м$^2$ | Гкал |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «КАМАЗ-Энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2016 | 5961,73 | X | 0 | X | 0,29 | 2150,56 |
| | | 2017 | X | 1 | 0 | X | 0,29 | 2150,56 |
| | | 2018 | X | 1 | 0 | X | 0,29 | 2150,56 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт
комитеты, Тарифлар буенча карарларны кабул итү,
оештыру һәм җайга салу бүлеге